Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

26 июль 2019 ел №306

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданы турында»гы 2006 елның 19 маендагы №72 карарына үзгәрешләр кертү турында

Хокукый мониторинг тәртибендә Әлмәт шәһәре прокуратурасының 2019 елның 25 июнендәге № 02-01-23/2019 таләпләрен карап тикшергәннән соң,

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Мактаулы гражданы турында» гы 2006 елның 19 маендагы №72 карарына (Әлмәт муниципаль районы Советының 2011 елның 28 апрелендәге №82, 2012 елның 30 маендагы №198, 2012 елның 19 октябрендәге №234, 2015 елның 23 октябрендәге №18, 2015 елның 29 декабрендәге №45, 2016 елның 10 августындагы №85, 2017 елның 25 сентябрендәге № 204 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- «Гомуми нигезләмәләр» 1 бүлегендәге 3 нче кушымтаның 1.4 пунктында «, кагыйдә буларак,» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Советының социаль мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә (Салахов И.Р.).

Муниципаль район
башлыгы урынбасары А.А. Зимин